Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге
Кече Колбай-Мораса авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Кече Колбай-Мораса авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Кече Колбай-Мораса авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән 1000 сум (бер мең сум) күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Кече Колбай-Мораса авылында су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Ә. Насыйбуллин

Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыбуллин